Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_________27.10.2025 Менделеевск ш. 660

Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп
коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны
килештерү һәм кабул итү комиссиясе
тарафыннан күпфатирлы йортта биналарны
яңадан үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан
планлаштыру турында актны рәсмиләштерү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында " 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 550 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта биналарны яңадан үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Административ регламентның 1.5 пунктындагы 6 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йорттагы бинаны яңадан планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән гыйбарәт, һәм (яисә) яңа биналар барлыкка килүдән, шул исәптән әлеге Кодексның 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планлаштырылуын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән). Яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә шулай ук чиктәш биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәрергә мөмкин. Планлаштыруны яңадан төзү биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы (биналары) турында яисә төзелгән биналарның дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру һәм төзелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә.»

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С. В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларны башкаручы А.Ф. Искаков